ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.10.2021 п.г.т.Алексеевское № 388

**2022 елга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

«Россия Федерациясендә белем бирү турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендәге 1 өлешенең 11 пункты, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрен финанслауны кертү хакында» 2007 елның 12 декабрендәге 482 номерлы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты карары нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2022 елга кушымтада бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

Алексеевск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар (Кушымта).

2. Муниципаль районының финанс-бюджет палатасы (Леденцов О.Н.) әлеге карарның 1 пункты белән расланган белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Симашевага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **А.В.Симашева**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2021 елның 25 октябрендәге
388 номерлы карарына
кушымта

**Алексеевск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, сум елына |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 97 391 |
| | авыл җирлеге | 98 753 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 143 889 |
| | авыл җирлеге | 143 363 |